КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 31 май г.Казань № 412

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Экологик иминлекне тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 27 февраль, 122 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Экологик иминлекне тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 27 февраль, 122 нче карары белән расланган конкурс комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 22 октябрь, 794 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Экологик иминлекне тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 27 февраль, 122 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 ел, 24 ноябрь, 898 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 7 август, 642 нче карарының 1 нче пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Экологик иминлекне тәэмин итүгә юнәлдерелгән иҗтимагый файдалы (социаль) проектларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы

бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 27 февраль, 122 нче карары белән расланган Экологик иминлекне тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү буенча конкурс комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 28 август, 703 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин